**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2025 елның 8 апрелендәге 1049 номерлы карары**

**Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесенең**
**2008 елның 30 апрелендәге 1937 номерлы**
**«Дубравная урамы, 35 адресы буенча урнашкан**
**махсуслаштырылган торак йортка урнаштыру турында»гы**
**карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Казан шәһәре, Дубравная урамы, 35 йорт адресы буенча урнашкан махсуслаштырылган торак йорттагы торак урыннарны гамәлдәге законнар нигезендә бүлү максатыннан **карар бирәм**:

1. Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесенең 2008 елның 30 апрелендәге 1937 номерлы «Дубравная урамы, 35 адресы буенча урнашкан махсуслаштырылган торак йортка урнаштыру турында»гы карарына (аңа Казан шәһәре Башкарма комитетының 2017 елның 5 сентябрендәге 3471 номерлы, 2020 елның 8 апрелендәге 1049 номерлы, 2021 елның 27 июлендәге 1821 номерлы, 2022 елның 27 декабрендәге 4675 номерлы, 2023 елның 30 ноябрендәге 3743 номерлы, 2024 елның 22 августындагы 3481 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1 номерлы кушымтада:

1.1.1. 2 пунктта «65 яшьтән яшьрәк булмаган (ир-атлар һәм хатын-кызлар)» сүзләрен «ир-атлар өчен 65 яшьтән яшьрәк булмаган һәм хатын-кызлар өчен 60 яшьтән яшьрәк булмаган» сүзләренә алмаштырырга;

1.1.2. 2 пунктны түбәндәге эчтәлекле абзац белән тулыландырырга:

«- Казан шәһәре Башкарма комитетында социаль наем шартнамәләре буенча торак урыннарга мохтаҗ буларак исәптә торучы гражданнар»;

1.2. 4 номерлы кушымтада:

1.2.1. комиссия составыннан Е.С.Митрошенкованы, Е.Н.Смагинаны чыгарырга;

1.2.2. комиссия составына аның әгъзалары сыйфатында түбәндәгеләрне кертергә:

- Смагина Елена Николаевна, Казан шәһәре Башкарма комитетының Торак сәясәте идарәсе башлыгы урынбасары;

- Трифонова Юлия Борисовна, Казан шәһәре Башкарма комитеты Торак сәясәте идарәсенең муниципаль торак фондын исәпкә алу һәм бүлү бүлеге башлыгы.

2. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары И.Ә.Гыйниятуллинга йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**



ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН